**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2014 ел, 30 декабрь № 1065

г. Казань

Татарстан Республикасының аерым дәүләт автоном учреждениеләрен кушылу рәвешендә үзгәртеп оештыру турында

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 ел, 28 декабрь, ФЗ-442 нче Федераль законны тормышка ашыру һәм аерым дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча «Гаилә» республика мәгълүмат-методик үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен һәм «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтү буенча «Зеркало» республика үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен, «Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика мәгълүмат-методик үзәге» дәүләт казна социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен (алга таба – казна учреждениесе) төзеп, бергә кушу рәвешендә үзгәртеп оештыру турындагы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

казна учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы башкара дип;

казна учреждениесе бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән үзгәртеп оештырыла торган учреждениеләрнең хокук дәвамчысы була дип;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат саны 164 берәмлек тәшкил итә дип;

казна учреждениесе эшчәнлегенең максаты булып халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына аларның эшчәнлеген фәнни-методик тәэмин итүдә булышлык күрсәтү, «Татарстан Республикасында социаль хәле куркыныч булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасын функциональ административлаштыру, социаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗ һәм гражданның социаль хезмәтләр күрсәтүгә, социаль хезмәтләр күрсәтү буенча

индивидуаль программа төзүгә булган индивидуаль ихтыяҗны билгеләү, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр һәм социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар реестрын төзү һәм алып бару буенча Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашу тора дип.

3. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

өч ай эчендә бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле булган, гамәлдәге законнар белән күздә тотылган чараларны үткәрүне, шулай ук казна учреждениесе уставын раслауны һәм дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләрне һәм компенсацияләрне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә бирүне тәэмин итәргә;

дәүләт мөлкәтен (шул исәптән күчемсез мөлкәт объектларына техник документларны) оператив идарә хокукында казна учреждениесенә беркетү өчен кирәкле документларны бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән учреждениеләр тарафыннан Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына үз вакытында кертүне тәэмин итәргә;

бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыру чараларын үткәрү чыгымнарын финанслауны социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары өлешендә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча күздә тотылган акча чикләрендә тәэмин итәргә;

ел саен казна учреждениесенә аның уставы белән күздә тотылган төп эшчәнлек нигезендә дәүләт йөкләмәсен расларга.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына казна учреждениесе уставын дәүләт теркәвенә алганнан соң:

бер ай эчендә бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән учреждениеләргә элек оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен оператив идарә хокукында казна учреждениесенә беркетергә.

элек бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән учреждениеләрнең күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында өч ай эчендә казна учреждениесенә бирүне тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, бу карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, бер ай эчендә Татарстан Республикасының тиешле норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

6. Татарстан Республикасының дәүләт казна учреждениесе эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары өлешендә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан

Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча күздә тотылган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2014\1065.doc